# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧҮРИ-БУРАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ

2018 ел, 10 сентябрь № 88

**Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

“Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турындагы Кодекс, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы “Чүри-Бураш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чүри-Бураш авыл җирлеге Советы карар итә:

1. Чүри-Бураш авыл җирлеге Советының 2016 ел, 12 февраль 27 нче номерлы карары белән расланган “Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында” Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 3.3. пунктында «өлкән» сүзен «әйдәп баручы, өлкән» сүзе белән алыштырырга;

б) 18.3. пунктында 2.1 өлешен түбәндәгечә тулыландырырга:

«2.1) кадрлар белән эшләүче хезмәтләр бүлегендә ришвәтчелекне һәм башка хокук бозуларны кисәтү, ришвәтчелек буенча фактик хәлләр ясау турындагы докладын, муниципаль хезмәткәрнең үзенең ризалыгы буенча ришвәтчелек кылуын тануын (ышанычны акламау сәбәпле, вазыйфасыннан азат итүдән тыш)

в) 20.6.пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20.6. 20.5.пунктында каралганча,бәйге үткәрү турындагы мәгълүматта, укып бетергәч, гражданнар тарафыннан алыштырылучы муниципаль хезмәт вазыйфалары курсәтелә; бу вазыйфаларга квалификацион таләпләр; 20.8. пункты буенча, бу бәйгегә кирәкле документлар һәм аларны кабул итү урыны, вакыты; күрсәтелгән документларны кабул итү срогы тәмамлану вакыты; бәйгенең үткәрелү вакыты, урыны, уздырылу тәртибе күрсәтелә; максатчан укыту турында килешү төзү өчен кандидатлар сайлау һәм бәяләү буенча бәйге процедуралары; язмача биремнең темасы (әгәр бәйге комиссиясенең бер процедурасы язмача бирем булса), тагын шулай ук башка мәгълүматлар булырга мөмкин.

г) 20.10. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“20.10. Конкурс комиссиясе претендентларның бирелгән документлары нигезендә 20.8 пункты 1 – 6 өлешендә курсәтелгәнчә бәяли, шулай ук конкурс процедуралары нәтиҗәсе буенча. Җирле үзидарә органы карары буенча, конкурс процедурасы индивидуаль әңгәмә, тестирование яки язмача бирем үткәрә.”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы Официаль порталына һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы официаль сайтының җирлекләр бүлегенә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Чүри-Бураш авыл**
**җирлеге башлыгы** **И.Р.Мифтахов**